БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» 09 2024 ел № 229

Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2023елның 27 октябрендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында бушлай туклану белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 271 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасының 2013 елның 22 июлендәге «Мәгариф турында» 68-ТРЗ номерлы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2023елның 27 октябрендәге «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында бушлай туклану бирү тәртибен раслау турында» 271 номерлы карарына, 1.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«- ата-анасы (уллыкка алучысы) беренче яисә икенче төркем инвалид булган яисә ата-анасының (уллыкка алучыларының) берсе беренче яисә икенче төркем инвалид булган һәм балаларны (баланы) мөстәкыйль тәрбияләгән (ата-анасының (уллыкка алучының) алимент түләү турындагы килешү нигезендә яки башкару кәгазе нигезендә алимент йөкләмәләре булганда), алар тулысынча яисә өлешчә үтәлмәгән булырга тиеш) ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) язма гариза нигезендә гражданның инвалидлыгы булуын раслый торган документның күчермәсен, алимент буенча бурычы булуын раслый торган документның күчермәсен тапшырып.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (baltasi.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов